Манзарас авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2023 елның 27 феврале №3

Манзарас авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Манзарас авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 2 ноябрендәге 32 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 14 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 9 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 15 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчаны өстәргә:

«12) алар тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

1) 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Манзарас авылы җирлек башлыгы Р.Г. Хәбибуллина